**СОВЕТ**
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Кооперативная, д. 22, с.Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Утар-Аты авыл җирлеге Советы**
**карары**

**« 15» январь 2025 ел** **№ 136**

**"Җир салымы турында" 2022 елның 22 августындагы 64 номерлы Утар-Аты авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (29.12. 2022 N 77, от 29.11.2023 № 103, от 25.11.2024 №132)**

12.07.2024 N 176-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге уставына таянып, Утар-Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. "Җир салымы турында" 2022 елның 22 августындагы 64 номерлы Утар-Аты авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Әлеге абзацта күрсәтелгән шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш, торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,1 процент».

2) 2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм аерым Россия Федерациясе закон актлары», әлеге пунктта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә;».

2. Әлеге карарның 1 пунктының гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында.

4. 01.01.2025 елдан Утар-Аты авыл җирлеге Советының 25.11.2024 №132 «Утар-Аты авыл җирлеге Советының «җир салымы турында»2022 елның 22 августындагы 64 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. 3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева

СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ